КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 апрель г.Казань № 218

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 август, 743 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 26 август, 743 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазландыру

өлешендә җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлеккә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Юл хәрәкәте иминлеген арттыру» процесслы чаралар комплексы паспортының Агымдагы елда процесслы чаралар комплексын гамәлгә ашыру планының 2.4 пунктында каралган Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларын юл билгеләре белән җиһазлау чараларын гамәлгә ашыру кысаларында бирелә.»;

12 пунктка «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма буенча» сүзләрен өстәргә;

13 пунктта:

дүртенче абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (нәтиҗәләре)» сүзләрен «нәтиҗәләре» сүзенә алыштырырга;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапларны тапшыру формасы һәм сроклары;»;

җиденче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләр) күрсәткеченә» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль берәмлек Министрлыкка финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисапны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча килешү төзүдә каралган срокларда Министрлыкка тапшырырга тиеш.»;

19 пунктта:

беренче абзацта «Файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече» сүзләрен «Бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләр) күрсәткеченә» сүзләрен «бирү нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

21 пунктта:

беренче абзацта «башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләрен «башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү һәм аңа ирешү максатларында кабул ителгән йөкләмәләр турында хисап» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «биру нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «биру нәтиҗәсенә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры .В.Песошин